СОВЕТ
БОЛЬШЕКУРГУЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ КАРАУҖА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ

16.10.2023

с.Большие
Кургузи

КАРАР

№ 141

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 28.12.2021 № 46 карары белән расланган Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында (Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 28.12.2022 №101 Карары белән кертелгән үзгәрешләр белән)

«Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 27.12.2018 № 498-ФЗ Федераль законнар, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 № 131-ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Карауҗа авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Олы Карауҗа авыл җирлеге Советы:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 28.12.2022 №46 карары белән расланган Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә (Олы Карауҗа авылы Советының 28.12.2022 №101 Карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба – кагыйдәләр) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1.1. Кагыйдәләрне түбәндәге эчтәлектәге 1 нче кушымта белән тулыландырырга:

Авыл җирлеге башлыгы

Р. Ф. Хөснетдинова

«1 нче кушымта
Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Советының 16.10.2023 № 141 карары белән расланган Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясен төзекләндерү кагыйдәләренә

Исемлек
Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге территориясендә хайваннарны хуҗасыз кайтару тыела торган урыннар"

1. Балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, актив спорт төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар.
2. Җәмәгать территорияләре (парклар, скверлар территорияләре, күпләп ял итү урыннары, гомуми файдаланудагы су объектларының яр буйлары).
3. Мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларга якын территорияләр.
4. Мәдәният һәм сәнгать объектларына якын территорияләр.
5. Җәмәгать туклануы оешмаларына, сәүдә объектларына, стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру урыннарына якын территорияләр.
6. Зират.».
2. Хайваннарны элеккеге яшәү урыннарына хуҗасыз кайтару турында Карар кабул итүгә вәкаләтле затларның түбәндәге исемлеген билгеләргә:
- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге башлыгы;
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының рәсми сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә, шулай ук Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Зеленодольск авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнашкан: Татарстан Республикасы, Зеленодольск районы, Олы Карауҗа авылы, Күпер урамы, 23 йорт (СДК бинасы), Зур Күлбаш авылы, Подгорная урамы, 26 йорт (СДК бинасы).
4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккач үз көченә керә.